ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 203

«Каратун – Чирмешән –Олы Подберезье» автомобиль юлы чикләрендә җир кишәрлекләренә даими гавами сервитут билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы нигезендә, муниципаль ихтыяҗларны һәм җирле халык ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Каратун – Чирмешән –Олы Подберезье» автомобиль юлы чикләрендә әлеге карарга кушымталарда каралган чикләрдә Татарстан Республикасы Апас һәм Кайбыч муниципаль районнарының торак пунктларына юлларны тәэмин итү өчен даими гавами сервитут билгеләргә:

16:21:000000:103 (:ЗУ1) кадастр номерлы җир кишәрлегенең 20340 кв.м мәйдандагы өлешенә;

16:21:000000:104 (:ЗУ1(2) кадастр номерлы җир кишәрлегенең 6291 кв.м мәйдандагы өлешенә;

16:21:000000:105 (:ЗУ1) кадастр номерлы җир кишәрлегенең 9814 кв.м мәйдандагы өлешенә;

16:21:030704:138 (:ЗУ1) кадастр номерлы җир кишәрлегенең 4416 кв.м мәйдандагы өлешенә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарга кушымталарда каралган чикләрдә гавами сервитутның гамәлдә булуы өлкәсендә тиешле белешмәләр кертү өчен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru

веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен когнтрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров